КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 сентябрь г.Казань № 930

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индивидуаль күрсәткечләрен, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеген һәм аларны ачыклау тәртибен раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индивидуаль күрсәткечләрен;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеген һәм аларны ачыклау тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характер-

дагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы;

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2016 ел, 3 октябрь, 710 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 8 август, 645 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 31 октябрь, 973 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 15 сентябрь, 832 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2016 ел, 3 октябрь, 710 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 8 декабрь, 1113 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин